ГЛАВА УСАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.4, с. Усали,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422174

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҮСӘЛИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Беренче май ур., 4 нче йорт, Үсәли авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422174

тел.(факс): (85563) 2-74-10; e-mail: Usal.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№ 6 — 30 октябрь 2019ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Владимир авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Усали авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Владимир авылы , Совет урамы , 72 нче йорт адресы буенча урнашкан Владимир авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 14 ноябрендә сәгать 13.00 дә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Владимир авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлегенең Владимир торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Владимир торак пунктында Октябрь урамы буенча баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;

- Владимир торак пунктында лампалар, яктырту җиһазларын кайтарту, договор буенча хезмәт күрсәтүгә түләү;

- Владимир торак пунктындагы юлларны, тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Усали авыл җирлеге башкарма комитетына Владимир авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Усали авыл җирлеге башлыгы: А.И.Зиатдинов